КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 2 октябрь г.Казань № 896

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен, әлеге бәяләү критерияләрен кертеп, бәяләү үткәрү тәртибен һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 20 пунктын һәм «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $9^1$ статьясын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен, әлеге бәяләү

критерияләрен кертеп, бәяләү үткәрү тәртибе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү тәртибе.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 2 октябрь, 896 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен, әлеге бәяләү критерияләрен кертеп, бәяләү үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 20 пункты һәм «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $9^1$ статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен, әлеге бәяләү критерияләрен кертеп, бәяләү үткәрү процедурасын билгели.

2. Медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүнең максаты булып медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату процедурасыннан соң тулаем алганда республикада һәм (яки) төгәл бер территориядә сәламәтлекне саклау системасы торышын һәм халыкның медицина хезмәтләренә ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен моннан соң барлыкка килгән шартларны билгеләү.

3. Медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критериясе булып муниципаль берәмлек территориясендә гражданнарга медицина ярдәме алу өчен шартларны саклау, шулай ук түбәндәгеләрне исәпкә алып, төгәл бер территорияне үстерүнең бүтән шартларны саклау:

әлеге муниципаль берәмлектә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, түләүсез медицина ярдәмен күрәтүгә дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыруда катнашучы башка медицина оешмаларында медицина ярдәмен алу мөмкинлеге булу;

әлеге муниципаль берәмлектә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, түләүсез медицина ярдәмен күрәтүгә дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыруда катнашучы башка медицина оешмаларының территориаль яктан якын булуы, шул исәптән транспорт белән барып җитүне исәпкә алып;

социаль-җитештерү шартлары (медицина оешмасы хезмәт күрсәтә торган территориядә гамәлдәге сәнәгать яки авыл хуҗалыгы предприятиеләре булу, аларның перспективалары, әлеге территориядә халык саны динамикасы), шулай ук мондый карар кабул ителгәннән соң әлеге территориядән яшәүчеләр китү мөмкинлеге фаразлары);

төбәк хезмәт базарының квалификацияле медицина кадрларына ихтыяҗ фаразы;

Татарстан Республикасында халык санының фараз күрсәткечләре, шул исәптән халык тыгызлыгы арту мөмкинлеге;

медицина оешмасының гамәлдәге матди-техник базасы (биналарның характеристикасы (төзү елы, бина төре һ.б.ш.), корылмаларның һәм аларның мәйданнарының санитария-техника нормаларына туры килүе; җир кишәрлекләре территорияләрен уңайлаштыру дәрәҗәсе; җиһазлар, корылмалар булу һәм аларның торышы һәм кабинетлар (залларны) җиһазлау, шулай ук билгеле булган үзгәрешләр белән бәйле мөлкәтне куллану перспективалары).

5. Медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү өчен медицина оешмасын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Комиссия рәисе адресына әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән критерияләр анализын исәпкә алып әзерләнгән медицина оешмасын бетерүнең, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктатуның максатка ярашлы булуын нигезләп, медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында язмача тәкъдим җибәрә, аңарга түбәндәге документларны терки:

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тапшырган демографик процесслар турында, төбәк хезмәт базарының квалификацияле кадрларга ихтыяҗ турында мәгълүматларны;

тиешле территориядә урнашкан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, түләүсез медицина ярдәмен күрәтүгә дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары турында мәгълүматларны;

медицина оешмасының матди-техник базасы турында, шул исәптән оператив идарә итү хокукында медицина оешмасына беркетелә торган (беркетелгән) мөлкәт турында, шулай ук күздә тотылган үзгәрешләр белән бәйле мөлкәтне куллану перспективалары турында мәгълүматларны;

медицина оешмасы урнашкан территориянең социаль-җитештерү шартлары турында мәгълүматларны;

медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату буенча чараларны финанслауга ассигнованияләр күләмен күрсәтеп, тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне финанс-икътисадый нигезләү;

әлеге мәсьәлә буенча медицина оешмасының күзәтүчеләр советы (автоном медицина оешмалары өчен), дәүләт-иҗтимагый идарә органы (бюджет һәм казна

медицина оешмалары өчен) тәкъдимнәре;

медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату нәтиҗәсендә эшсез калган хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүматларны;

йомгак документта (беркетмәдә) чагылыш тапкан җәмәгать (ачык) тыңлаулары нәтиҗәләре буенча авыл торак пунктында яшәүчеләр фикере (авыл җирлегендә урнашкан медицина оешмасын бетергәндә, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктатканда).

6. Медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында тәкъдимне һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны алар кергән көндә Комиссия секретаре терки.

7. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән барлык раслый торган документлар тулы күләмдә тапшырылмаган очракта Комиссия секретаре медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында тәкъдимне һәм документларны (мәгълүматларны) теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә медицина оешмасын бетерү һәм аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү үткәрү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) соратып ала.

Соратуны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә медицина оешмасын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган җитмәгән документларны Комиссия рәисе адресына җибәрә.

8. Комиссия рәисе әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән барлык документларны (мәгълүматларны) теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели һәм кирәкле материалларны Комиссия әгъзаларына җибәрә.

Комиссия утырышы әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән барлык документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә үткәрелергә тиеш.

9. Медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү Комиссия тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән әлеге бәяләү критерияләреннән чыгып, түбәндәгеләр белән гамәлгә ашырыла:

медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату чараларының социаль-икътисадый нәтиҗәләрен һәм финанслар ягыннан нигезле булуын бәяләү;

медицина оешмасы эшчәнлеге сыйфатын һәм матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсен бәяләү;

бетерелә торган медицина оешмасы, аның эшчәнлеге туктатыла торган аерымланган бүлекчәсе хезмәткәрләре һәм пациентларының законнарда билгеләнгән хокукларын һәм гарантияләрен саклауны бәяләү.

10. Комиссия тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, медицина оешмаларына медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү үткәрү өчен кирәкле өстәмә мәгълүмат, өстәмә материаллар һәм барлык раслый торган документларны тапшыру турында соратулар җибәрергә хокуклы.

11. Комиссия бәяләмәсе Комиссия утырышын үткәргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә медицина оешмасын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга җибәрелә.

Комиссия бәяләмәсендә әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән критерияләрдән чыгып, әлеге бәяләү критерийләрен кертеп, медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен әлеге Комиссия тарафыннан уңай яки тискәре бәяләүне нигезләү күрсәтелергә тиеш.

12. Медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләренә Комиссиянең тискәре бәяләмәсен алганда тиешле карар кабул итү нәтиҗәләрен тискәре бәяләүгә сәбәпләр булмаганда медицина оешмасын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган тиешле тәкъдим белән Комиссиягә кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 2 октябрь, 896 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 20 пункты һәм «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $9^1$ статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия (алг таба – Комиссия) төзү процедурасын билгели.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яки җирле үзидарә органы ведомствосындагы медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү үткәрү өчен төзелә.

3. Комиссия һәр бетерелә торган медицина оешмасы һәм медицина оешмасының эшчәнлеге туктатыла торган аерымланган бүлекчәсе өчен төзелә.

4. Комиссия составы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана.

5. Комиссия составына паритетлы нигездә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, территориясендә медицина оешмасы яки аның эшчәнлеге туктатыла торган аерымланган бүлекчәсе урнашкан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, җирле үзидарәнең медицина оешмасын, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 76 статьясындагы 1 өлештә күрсәтелгән медицина һөнәри коммерциячел булмаган  медицина оешмасын һәм сәламәтлек склау өлкәсендә  гражданнар хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләрен гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органы вәкилләре керә.

6. Комиссияне Комиссия рәисе, ә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары җитәкли.

7. Комиссия карарлары Комиссия утырышы көнендә бәяләмә белән рәсмиләштерелә, аңарга Комиссия рәисе яисә ул булмаганда рәис урынбасары һәм

секретарь имза куя.

8. Комиссия рәисе Комиссия эшен планлаштыра, Комиссия утырышларын билгели һәм алып бара.

9. Комиссия секретаре Комиссия утырышларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру һәм техник эшләрне, шул исәптән Комиссия каравына тапшырыла торган документларны (мәгълүматларны) тикшерүне гамәлгә ашыра, шулай ук Комисси утырышы нәтиҗәләре буенча аның бәяләмәләрен, беркетмәләрен рәсмиләштерә.

10. Комиссия утырышларында бетерелә торган медицина оешмаларының, медицина оешмаларының эшчәнлеге туктатыла торган аерымланган бүлекчәләренең вазыйфаи затлары, Комиссия рәисе карары буенча чакырылган бүтән затлар катнаша.

11. Комиссия утырышы, анда әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы санала.

12. Комиссия бәяләмәләре аның утырышында катнашучы әгъзаларының ачык тавыш бирүдә гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе тавышы хәл иткеч була.

13. Комиссия бәяләмәләре Комиссия рәисе яисә  ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары  һәм секретаре тарафыннна имзалана.

---